Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Аксаринского сельского
поселения Заинского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Аксар авыл җирлегенең
башкарма комитеты

Ул. Ленина, д.42А с. Аксарино,
Заинский район, 423501

Ленин урамы, 42А нче йорт, Аксар
авылы, Зәй районы, 423501

Телефон, факс 3-73-42. Электронный адрес: Aks.zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/aksarinskoe.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№15 24.08.2022г.

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 апрелендәге 08 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләренең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия ФедерациясеХөкүмәтекарары нигезендә,Зәй муниципаль районыныңАксар авыл җирлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 апрелендәге 08 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1 бүлекнең 3 пунктында « муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 3 бүлектә:

а) 12 пунктның икенче абзацында« муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«соңгы 5 ел вакыт эчендә ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләрнең саны һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны нисбәтебелән характерлана торган түләүчеләрнең бирелгән ташламаларга ихтыяҗы яисә түләүчеләрнең гомуми саны.»;

в) 12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Түләүчеләрнең бирелгән ташламаларга ихтыяҗын бәяләүне уздыру максатларындасалымчыгымнары кураторы тарафыннанташламага ихтыяҗ дип таныла торган әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән нисбәтнең минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин»;

г) түбәндәге эчтәлекле 15.1 пункт өстәргә:

«15.1. Кирәк булганда салым чыгымнары кураторы тарафыннан муниципаль берәмлек салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 16.1 пунктны өстәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.».

2.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **Ю.И.Гильманов**